ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.07.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№1465**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016-2026 елларга ишегалды стандарты» муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016-2026 елларга ишегалды стандарты» муниципаль адреслы программасына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 1 февралендәге 155 номерлы, 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы, 2018 елның 30 маендагы 1169 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 2335 номерлы, 2019 елның 16 апрелендәге 895 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) әлеге карарга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Кушымта
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
карарына

18.07.2019 №1465

**Программаның паспортында «Күләме һәм финанслау чыганаклары» пунктының 6 нче графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** «Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».